**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«08» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толл калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төрнәс авылы юлларын сезонлы карап тоту);

Төрнәс авылының урам утлары җиһазларын көйләү;

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважиналарны лицензияләү, Төрнәс авылында су белән тәэмин итү системаларын агымдагы ремонтлау);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү өчен су саклау савытын сатып алу);

торак пункт территориясен төзекләндерү (Төрнәс авылында Садовая, Школьная, Центральная урамнары).

Халык җыенында рәислек итүче: С.В. Белов

Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В. Белов